**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АКТАНЫШ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
423740, Актаныш авылы,
Ленин проспекты, 58 нче йорт.
тел (85552)3-44-40

e-mail:
Akt.Ak@tatar.ru

**АКТАНЫШСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
423740, село Актаныш,
Проспект Ленина,
дом 58., тел. (85552)3-44-40

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 9 08.04.2026 ел

**Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге хезмәткәрләренең эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 15 февралендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Актаныш районы прокурорының 27.03.2026 ел № 02-08-02-2026/Прдп101-26-20920005, номерлы протестын карап, Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл башкарма комитеты хезмәткәрләренең эчке хезмәт тәртибе Кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 14 февралендәге 5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче кисәккә түбәндәге эчтәлекле 2.14_1 пунктчасы өстәргә:

«2.14_1. Һәлак булган (вафат булган) сугышчан хәрәкәтләр ветеранының кабат никахка кермәгән (өйләнмәгән) хатыны (ире) белән хезмәт шартнамәсен эш бирүче инициативасы белән өзү сугышчан хәрәкәтләр ветераны һәлак булган (үлгән) мизгелдән соң бер ел дәвамында рөхсәт ителми (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 81 статьясындагы беренче өлешенең 1, 5 - 8, 10 яисә 11 пунктларында яисә 336 статьясындагы 2 пунктында каралган нигезләр буенча эштән азат ителүдән тыш).»

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Актаныш муниципаль районы
Актаныш авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе К.Н.Әхмәтгалиев